**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге Яңа Елховой торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлеге Яңа Елховой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә:

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә::

1. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- МТЗ-81.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәтләре өчен түләү).

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-юлдагы чокырларны ремонтлау (Родничная урамында).

3 Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Чишмәле урамы, 2, Яңа Елховой авылы Авангард урамы, 23 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф. Хәбибуллин